КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 октябрь г.Казань № 854

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 сентябрь, 940 нчы; 2023 ел, 6 март, 212 нче; 2023 ел, 29 май, 652 нче, 2023 ел, 4 август, 945 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 4 октябрь, 854 нче карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия (алга таба - субсидия) бирү максатларын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

вәкаләтле орган - Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучы буларак тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелде бюджет акчаларын баш бүлүче функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

вәкаләтле оешма - үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан

Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 04 март, 132 нче карары нигезендә гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе

килешү - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма буенча субсидия алучы һәм вәкаләтле орган арасында төзелгән субсидия бирү турында килешү;

индустриаль (сәнәгать) парк – сәнәгать инфраструктурасы объектлары җыелмасы, ул тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы һәм (яки) муниципаль берәмлек милкендәге һәм (яки) хосусый милектәге күчемсез мөлкәт объектларын, шул исәптән парк эшчәнлеген тәэмин итә торган, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары эше өчен шартлар тудыруга һәм сәнәгать җитештерүен гамәлгә ашыруга билгеләнгән һәм идарәче компания тарафыннан идарә ителә торган җир кишәрлекләрен, административ, җитештерү, склад һәм башка бүлмәләр, инженерлык, һәм (яки) энергетика, һәм (яки) транспорт инфраструктурасы объектларын үз эченә ала;

электр энергиясен китерүче оешма - мөрәҗәгать итүченең электр энергиясен китерүгә шартнамәчел мөнәсәбәте булган оешма (энергия белән тәэмин итү (сату-алу) шартнамәсе, китерү шартнамәсе);

мөрәҗәгать итүчеләр - «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентлары һәм идарәче компанияләре булган, электр энергиясе белән тәэмин итүче оешма белән шартнамәчел мөнәсәбәтләргә ия булган сайлап алуда катнашучылар;

идарәче компания - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибе нигезендә аккредитация алган хуҗалык җәмгыяте, крестьян (фермер) хуҗалыгы формасында эшләүче юридик зат булган яки кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы объекты милекчесе булган яисә аның белән идарә итүне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар булган кече һәм урта эшкуарлык субъекты;

резидент - Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән һәм тиешле идарә компаниясе белән төзелгән шартнамә (яисә башка законлы нигез) нигезендә кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы эшкуарлык субъекты;

сайлап алу җиңүчесе - әлеге Тәртипнең таләпләренә һәм критерийларына туры килә торган, кергән заявкаларны ранжировка нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 4.6 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән бүленә торган субсидия күләме чикләрендә сайлап алу йомгакларын чыгару беркетмәсенә кертелгән мөрәҗәгать итүче;

субсидия алучы - вәкаләтле орган белән килешү төзегән сайлап алуда җиңүче;

хисап кварталы - сайлап алуны уздыру кварталына кадәрге квартал;

иминләштерелгән затлар - мәҗбүри пенсия иминләштерүе һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри социаль иминләштерү тарала торган затлар.

1.3. Субсидияләр алучыларны сайлап алуны (алга таба – сайлап алу) үткәрү алымы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу – сайлап алуны мөрәҗәгать итүчеләрнең сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып уздыру.

Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

1.4. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны каплау.

1.5. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү» төбәк проектын гамәлгә ашыру максатларында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре, вәкаләтле органның бюджет чараларын баш бүлүче буларак  тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет акчасын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.6. Кире кайтару өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләренә сайлап алу үткәрелә торган елга кадәрге елда кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарга түләү буенча фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнарның бер өлеше керә.

1.7. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## II. Мөрәҗәгать итүчеләргә таләпләр һәм сайлап алу критерийлары

2.1. Мөрәҗәгать итүче заявка каралган һәм килешү төзелгән даталарга түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында

башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

эшчәнлекнең бер төре файдалы казылмаларны җитештерү һәм (яисә) сату, шулай ук чыгару һәм (яисә) сату, гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм эчәргә яраклы минераль сулардан тыш, файдалы казылмаларны җитештерү һәм (яисә) сату түгел, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса;

кредит оешмасы, иминият оешмасы (кулланучылар кооперативыннан тыш), инвестиция фонды, дәүләтнеке булмаган пенсия фонды, кыйммәтле кәгазьләр базарының профессиональ катнашучысы, ломбард булып тормый;

продукцияне бүлү турындагы килешүләрдә катнашмый;

уен бизнесы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмый;

Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә каралган очраклардан тыш, валютаны җайга салу һәм валюта контроле турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе нерезиденты булып тормый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә түгел;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юк;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

заявка бирүче юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның заявка бирүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел,

аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшкуар үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмаган һәм аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән.

Мөрәҗәгать итүченең әлеге пункт нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле органның, вәкаләтле оешманың файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта вәкаләтле орган, вәкаләтле оешма мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән вәкаләтле органга тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта мөрәҗәгать итүченең әлеге әлеге пунктта билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.2. Мөрәҗәгать итүче түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

заявка бирелгән датага кече яки урта эшкуарлык субъекты булып тора;

заявка биргән датага индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында вәкаләтле орган белән гамәлдәге килешүгә ия;

Федераль салым хезмәтенә хисап кварталы өчен Федераль салым хезмәтенең «Физик затлар турында иминият кертемнәре һәм персоналаштырылган белешмәләр, аларны тутыру тәртибе, шулай ук аларны электрон рәвештә тапшыру форматлары буенча исәп-хисап формаларын раслау турында» 2022 елның 29 сентябрендәге ЕД-7-11/878@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча физик затлар турында шәхси белешмәләр бирә;

сайлап алуны үткәрү елыннан алдагы елда электр энергиясе белән тәэмин итүче оешмага кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләүне гамәлгә ашырды һәм көчәнешнең түбәндәге диапазоннарының (дәрәҗәләренең) электр энергиясен кулланучы булды:

көчәнешнең уртача беренче диапазоны (дәрәҗәсе) (алга таба - СН-I),
көчәнешнең уртача икенче диапазоны (дәрәҗәсе) (алга таба - СН-II),
көчәнешнең түбән диапазоны (дәрәҗәсе) (алга таба - НН).

## III. Субсидия бирүгә документлар әзерләү

3.1. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

3.1.1. Мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматны:

мөрәҗәгать итүченең тулы һәм кыскартылган исеме (юридик затлар өчен);

индивидуаль эшкуар фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

мөрәҗәгать итүченең төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

муниципаль берәмлекләр территорияләренең гомумроссия классификаторы;

юридик зат адресы, теркәлү адресы (индивидуаль эшкуарлар өчен);

элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

юридик зат җитәкчесе турында мәгълүматны (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

мөрәҗәгать итүче тибы (резидент, идарәче компания);

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат.

3.1.2. Мәгълүматны һәм мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар.

3.1.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мөрәҗәгать итүче турында, бирелгән гариза турында мәгълүматны, шулай ук «Электрон бюджет» системасының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән субсидия бирүгә һәм аны сайлап алуга бәйле мөрәҗәгать итүче турында башка мәгълүматны бастырып чыгару (урнаштыру) ризалыгы.

3.1.4. Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәсе, соратып алына торган субсидия күләме.

3.2. Мөрәҗәгать итүче сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявкаларны «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштыра һәм тапшыра, түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) «Электрон бюджет» системасында күчереп кертә:

мөрәҗәгать итүченең заявка биргән датага әлеге Тәртипнең 2.1 һәм 2.2 пунктлары нигезләмәләренә туры килүен раслый торган, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гарантияле хаты;

электр энергиясе белән тәэмин итүче оешма белән төзелгән, электр энергиясе белән тәэмин итүче оешма тарафыннан таныкланган энергия белән тәэмин итү шартнамәсе (кушымталарсыз);

сайлап алуны үткәрү елыннан алдагы елда СН-I, СН-II, НН көчәнешнең асылда куллану диапазоны (дәрәҗәсе) турында, шулай ук көчәнешнең югары диапазоны (дәрәҗәсе) турында мәгълүмат булган электр куллануның ведомосте (электр энергиясе белән тәэмин итүче оешма тарафыннан таныкланган);

сайлап алуны үткәрү елыннан алдагы елда кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны раслаучы түләү йөкләмәләре (түләүне гамәлгә ашырган кредит оешмасы тарафыннан таныкланган);

устав (юридик затлар өчен);

Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләрен, шулай ук яшәү урыны турында белешмәләр булган битләр (шәхси эшкуарлар, юридик затларның законлы вәкилләре, ышанычнамә буенча вәкаләтле затлар өчен);

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык) яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында теркәү кәгазе (Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында теркәү кәгазе);

салым органында исәпкә куелу турында таныклык яки хәбәрнамә;

юридик зат исеменнән ышанычнамәдән һәм (яисә) вәкаләтләрне тапшыру турында шартнамәдән башка эш итү хокукы булган затны билгеләү турында беркетмә яисә боерык;

хисап кварталы өчен иминият кертемнәре буенча исәп-хисап (электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештә хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турындагы документларны электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турында салым органы тамгасы белән тапшырыла);

әлеге Тәртип кысаларында заявка биргән затның заявка мөрәҗәгать итүче исеменнән бирү һәм заявка составына керүче документларны имзалау хокукы булуын раслый торган Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (заявканы ышанычнамәсез эш итәргә хокукы булмаган зат тарафыннан мөрәҗәгать итүче исеменнән бирелгән очракта);

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон рәвештә бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 30 ноябрендәге ЕД-7-8/1129@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча агымдагы елның 1 гыйнварыннан заявка бирелгән датага кадәр биш календарь көнгә тигез теләсә кайсы датага бирелгән салым түләүче, җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче яки салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында күчерелгән акча суммасының кемгә каравы турында салым органының белешмә кәгазе;

һәр түләү йөкләмәсе яктылыгында кайсы чор өчен акча түләнү турында мәгълүмат бирелгән, заявкага теркәлгән түләү йөкләмәләренең номеры һәм датасы күрсәтелгән, вәкаләтле затның имзасы һәм заявка бирүченең мөһере (булганда) белән расланган аңлатма язуы.

3.3. Вәкаләтле оешма «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә түбәндәге белешмәләрне һәм документларны ала:

заявка биргән датага торышы буенча бирелгән Юридик затларның (индивидуаль эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

заявка бирү датасына бирелгән торышы буенча Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан өземтә;

заявка биргән датага салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычлары үтәлү турында салым органының белешмәсе;

вәкаләтле орган белән индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү.

3.4. Чит телдәге документларны мөрәҗәгать итүче, аларның рус теленә тәрҗемәсе белән бергә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган килеш тапшыра.

3.5. Вәкаләтле органның, вәкаләтле оешманың мөрәҗәгать итүче белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүченең «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган «Электрон бюджет» системасында вәкаләтле оешманы сайлап алуны уздыру вәкаләтләрен тапшыра. Вәкаләтле оешманың вәкаләтләре исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчеләрнең һәм алар тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 2.1, 2.2, 3.1 - 3.5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүен тикшерүне уздыру;

вәкаләтле орган раслаган форма буенча тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат формалаштыру.

Электрон рәвештә тапшырыла торган барлык документлар барлык пунктлар буенча тутырылырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела).

Электрон рәвештә тапшырыла торган кәгазь документ электрон формага төсне тулысынча бирү режимында сканерлау юлы белән электрон рәвешкә үзгәртелергә тиеш.

Мөрәҗәгать итүче заявканы «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи, «Электрон бюджет» системасында әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында каралган документларның электрон күчермәләрен тапшыра һәм заявкага мөрәҗәгать итүче яисә ул вәкаләт биргән зат җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза сала.

Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

Заявкага кертелгән фотоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче бер генә заявка бирергә хокуклы.

3.6. Тапшырыла торган белешмәләрнең дөрес булмавы, шулай ук ялган документлар өчен заявка бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

3.7. Заявканы әзерләгәндә барлыкка килә торган барлык куркынычлар һәм чыгымнар мөрәҗәгать итүчедә була.

## IV. Заявкаларны кабул итү һәм карау тәртибе

4.1. Сайлап алуны уздыру турында игълан вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейс формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзелә, вәкаләтле орган (ул вәкаләт биргән зат) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу үткәрелә башлаган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

Сайлап алуны уздыру турында игълан түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта заявкаларны кабул итеп алу тәмамлану датасы  сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 5.7 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

мөрәҗәгать итүче әлеге Тәртип белән билгеләнгән датага туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә  һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

заявкалар бирү тәртибен һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 4.4 – 4.6 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә (җиңүчеләргә) бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) килешү имзаларга тиешле вакыт;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартын;

бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

4.2. Заявканы тәкъдим итү датасы дип мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон бюджет» системасында теркәү номерын биреп, имза кую көне санала.

Заявкага аны теркәгәннән соң үзгәрешләр кертү һәм эшләп бетерүгә кире кайту рөхсәт ителми.

Мөрәҗәгать итүче заявканы «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыру тәмамланган көнгә кадәр теләсә кайсы вакытта чакыртып алырга хокуклы. Кирәк булганда мөрәҗәгать итүче заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап, мөрәҗәгать итүче, сайлау тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Вәкаләтле органга иң күбе биш гарызнамә җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган әлеге әлеге пунктта күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату күрсәтелгән белдерүдә булган мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пункт нигезендә мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

4.3. Вәкаләтле органга һәм вәкаләтле оешмага «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында игъланда билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганчы бер дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Вәкаләтле органга һәм вәкаләтле оешмага «Электрон бюджет» системасында бирелгән заявкаларга керү ачыла.

Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

4.4. Вәкаләтле оешма «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә мөрәҗәгать итүчеләрне һәм алар тапшырган документларны әлеге Тәртипнең 2.1, 2.2, 3.1 - 3.5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүенә тикшерә һәм вәкаләтле орган раслаган форма буенча тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматны туплый.

Вәкаләтле орган заявкаларны һәм «Электрон бюджет» системасында вәкаләтле оешмадан тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат кергән көннән соң 15 эш

көненнән артмаган срокта әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны карый.

Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук һәр мөрәҗәгать итүче буенча аның заявкасын туры килү хакында яки, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

Заявканы алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

мөрәҗәгать итүченең бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган заявканың һәм (яки) документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң заявка бирү;

заявка бирүченең әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган сайлап алу критерийларына туры килмәве.

Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда урнаштырыла.

4.5. Заявка бирүчегә бирелә торган субсидия күләме ($S_{гомуми}$) вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_{общ} = S_1 + S_2,$$

монда:

$S_1$ – бер ставкалы тариф буенча кулланылган электр энергиясе расходларына түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия күләме (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) сум, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_1 = \sum W_{факт\ i} \times \left(T_{факт\ i} - T_{вн\ i}\right),$$

монда:

$W_{факт\ i}$ – әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документ нигезендә заявка бирүчегә элегрәк субсидия бирелмәгән i аенда фактта кулланылган электр энергиясенең (югары көчәнеш диапазонлы (дәрәҗәле) электр энергиясеннән тыш) күләме, кВт × сәг; Par101

$Т_{факт\ i}$ – i аена Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәрле оешмалар челтәрләре буенча электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә бердәм (пар казаннары) тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 19 декабрендәге 3-26/э номерлы карарының (алга таба – Карар) 1 нче кушымтасында билгеләнгән, заявка бирүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документлар нигезендә i аенда заявка бирүченең фактта файдаланылган көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча түләнә торган бердәм (пар казаннары) тарифлар (ы), сум/кВт сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);Par101

$Т_{вн\ i}$ – Карар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә югары көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча челтәрле оешмалар челтәрләреннән билгеләнгән чорга башка кулланучылар тәэмин итеlә торган электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен i аена Карарда билгеләнгән бердәм (пар казаннары) тарифлар(ы), сум/кВт × сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$S_2$ – ике ставкалы тариф буенча кулланылган электр энергиясе расходларына түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия күләме (өстәлгән кыймматкә салымнан башка), сум, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_2 = \sum \Big(M_{факт\ i} \times \big(T1_{факт\ i} - T1_{вн\ i}\big) + W_{факт\ i} \times \big(T2_{факт\ i} - T2_{вн\ i}\big)\Big),$$

монда:

$М_{факт\ i}$ – әлеге Тәртипнең 3.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документ нигезендә заявка бирүчегә әлегрәк субсидия бирелмәгән i аенда электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә тариф ставкасы буенча фактта кулланылган актив куәтнең (югары көчәнеш диапазонлы (дәрәҗәле) электр энергиясеннән тыш) күләме, кВт × ай;

$Т1_{факт\ i}$ – электр челтәрләрен карап тоту өчен i аена Карарда билгеләнгән, әлеге Тәртипнең 3.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелгән документ нигезендә заявка бирүче тарафыннан аның фактта файдаланылган көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча түләнә торган ставка, сум/кВт × ай (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$Т1_{вн\ i}$ – югары көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча электр челтәрләрен карап тоту өчен i аена билгеләнгән, Карарда каралган ставка, сум/кВт × ай (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$W_{факт\ i}$ – әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документ нигезендә заявка бирүчегә әлегрәк субсидия бирелмәгән i аенда фактта кулланылган электр энергиясенең (югары көчәнеш диапазонлы (дәрәҗәле) электр энергиясеннән тыш) күләме, кВт × сәг; Par101

$Т2_{факт\ i}$ – электр челтәрләрендәге технологик расходка (югалтуга) түләү өчен i аена Карарда билгеләнгән, әлеге Тәртипнең 3.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелгән документ нигезендә заявка бирүче тарафыннан аның фактта файдаланылган көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча түләнә торган ставка, сум/кВт × сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$Т2_{вн\ i}$ – югары көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча электр челтәрләрендәге технологик расходка (югалтуга) түләү өчен i аена билгеләнгән, Карарда каралган ставка, сум/ кВт × сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып).

Субсидия күләме әлеге Тәртипнең 3.2 пункты нигезендә тапшырыла торган документларга таянып исәпләп чыгарылган, фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнар күләменнән арта алмый.

4.6. Субсидия бирү турында вәкаләтле орган карары автомат рәвештә сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм “Электрон бюджет” системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куйган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла, һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән заявка бирүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән заявка бирүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидияләр алучыларның исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидияләрнең күләме.

4.7. Бюджет йөкләмәләренең бүлеп бирелгән лимитлары әлеге Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә исәпләнгән күләмдә субсидия бирү өчен җитәрлек булмаса, вәкаләтле орган сайлап алуда җиңүчегә заявкада күрсәтелгән электрон почтага яисә «Электрон бюджет» системасы аша сайлап алу нәтиҗәләрен чыгару беркетмәсе урнаштырылган көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә субсидия күләмен киметү турында хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә) җибәрә. Сайлап алуда җиңүче тарафыннан бюджет йөкләмәләре лимитларының калган өлеше күләмендә субсидия алуга ризалык бирү турында карар кабул ителгән очракта сайлап алуда җиңүче әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә хәбәрнамә алган көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле органның хәбәрнамәдә күрсәтелгән электрон почтасына яисә «Электрон бюджет» системасы аша әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә ризалык (алга таба - ризалые) җибәрә.

Сайлап алуны җиңүче әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта ризалыкны тапшырмаган очракта вәкаләтле орган сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе нигезендә сайлап алуның исемлек буенча икенче җиңүчесенә, килештерүне тапшырмаган көннән исәпләнә торган, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокларда хәбәрнамә җибәрә.

4.8. Сайлап алуда җиңүче субсидия алудан баш тарткан очракта яисә әлеге Тәртипнең 4.9 пунктының дүртенче абзацы нигезендә сайлап алуда җиңүчегә баш тартылган очракта яисә сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән читләшкән дип танылган очракта бюджет йөкләмәләренең бушаган лимитлары сайлап алу йомгаклары буенча сайлап алу беркетмәсендә урнашу тәртибе буенча сайлап алуның соңгы җиңүчесеннән соң рейтингта киләсе урын алган сайлап алу җиңүчесенә беркетелә. Шул ук вакытта субсидия алудан баш тарту, әлеге Тәртипнең 4.9 пунктының дүртенче абзацы нигезендә сайлап алуда җиңүчегә баш тарту, сайлап

алуда җиңүчене килешү төзүдән читләшкән дип тану факты билгеләнгән көннән алып 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган бушаган лимитларны бүлү турында карар кабул итә.

4.9. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 3.1 һәм 3.2 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;

әлеге Тәртипнең 4.7 пунктында күрсәтелгән срок чыкканга кадәр сайлап алу җиңүчесе тарафыннан, бюджет йөкләмәләренең җитәрлек күләмдә булмавына бәйле рәвештә субсидия күләмен киметү турындагы хәбәрнамәгә җавап итеп, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча язмача ризалыгы бирелмәү;

бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

4.10. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда сайлап алуны үткәрүне юкка чыгара:

әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә заявкалар кабул итү чорында сайлап алуда катнашуга бер генә заявка да бирелмәгән булса;

әлеге Тәртипнең 1.5 пункты нигезендә әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире алу.

4.11. Сайлап алуны узмаган дип тану нигезләре:

әлеге Тәртипнең 2.1, 2.2 пунктларында каралган таләпләргә һәм критерийларга бер генә мөрәҗәгать итүченең дә туры килмәве;

тапшырылган заявкаларның һәм документларның әлеге Тәртипнең 3.1, 3.2 пунктларында каралган таләпләргә туры килмәве.

4.12. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару яисә сайлап алуны узмаган дип тану турында мәгълүмат сайлауны юкка чыгару яисә узмаган дип тану нигезләре билгеләнгән көннән соң өч эш көне дәвамында вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзелә, вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салына, «Электрон бюджет» системасында урнаштырыла, шулай ук вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыга. Сайлап алу мәгълүмат урнаштырылган көннән юкка чыгарылган яки узмаган дип санала.

Заявкалар биргән заявка бирүчеләргә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару яки сайлап алуны үтмәгән дип тану турында хәбәр ителә.

## V. Субсидия бирү тәртибе

5.1. Субсидия сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре буенча бирелә.

5.2. Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән алып җиде эш көне эчендә вәкаләтле орган сайлап алуда җиңүче белән килешү төзи. Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә

төзелә һәм  һәр як исеменнән эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салына.

5.3. Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы  белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә «Электрон бюджет» системасында килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

5.4. Сайлап алу җиңүчесе әлеге Тәртипнең 5.2. пунктында күрсәтелгән вакытта килешүгә кул куймаган очракта, ул килешү төзүдән читләшкән дип санала.

5.5. Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, вәкаләтле органга моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт кертелә.

Юридик зат булган субсидияне алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар булган, үз хокукларын башка гражданга «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә  тапшыра торган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда килешүгә, хокук варисы булган  башка зат килешүендә якларны күрсәтеп, затны үзгәртү өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

5.6. Субсидия вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган субсидия алучының исәп-хисап яисә хәбәрлек счетларына акчаларны күчерү юлы белән вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта бирелә.

5.7. Субсидия бирү нәтиҗәсе - заявка биргәндә тапшырылган хисап кварталы өчен иминият кертемнәре буенча исәп-хисапта күрсәтелгән күрсәткечләрнең 30 процентында рөхсәт ителгән иминләштерелгән затларның уртача исемлек санын саклап калу.

Хисап кварталыннан соң килүче квартал субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен хисап чоры булып тора. Субсидия алучы «Электрон бюджет» системасында хисап чорындагы субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне бәяләү өчен, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип  формасына ярашлы рәвештә форма буенча  субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра, хисап кварталыннан соң килә торган кварталга иминият кертемнәре буенча исәп-хисапны теркәп (электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештә хисаплылыкны кабул итү яисә кабул итү турында документларны теркәп, һәм тикшерү турындагы  салым органы билгесе белән тапшырыла). Хисап чорында субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап Россия Федерациясе Салым кодексының 431 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнгән иминият кертемнәре буенча исәп бирү  срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә бирелә.

Вәкаләтле орган «Электрон бюджет» системасында бирелгән көннән алып 30 эш көне эчендә субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылыкны тикшерә.

## VI. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыруга таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

6.1. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

6.2. Тәкъдим ителгән субсидия субсидия алучы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә хисаплана торган 10 көнлек чорда кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча да - тулы күләмдә;

әлеге Тәртипнең 5.7 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешмәү - тулы күләмдә;

субсидия алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмау - тулы күләмдә.

Субсидия алучы тарафыннан акчаларны кире кайтару өчен билгеләнгән срок бозылганда, вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидияне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кире кайтару чараларын күрә.

6.3. Почта һәм банк реквизитлары, элемтә телефоны номерлары, гамәлгә куючылар һәм җитәкче затлар составы үзгәрү, салым исәбенә кую урыны үзгәрү, гамәлгә кую документларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессын (субсидия алучылар - юридик затлар өчен) башлап җибәрү, шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлекне туктату яки банкротлык (субсидия алучылар - шәхси эшмәкәрләр өчен) процессын башлау очракларында, субсидия алучы әлеге вакыйгалар башланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу хакта язма рәвештә вәкаләтле органга хәбәр итәргә тиеш.

6.4. Субсидия алу өчен тапшырылган документларның дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык субсидия алучыга йөкләнә.

6.5. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән рәвештә билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Гарантия хаты

______________________________________________________________
(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))
_______________________________________________ йөзендә (алга таба –
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))
заявка бирүче),
_______________________________________________ нигезендә эш итүче
(уставның, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәү турында таныклык яки язу кәгазе, ышанычнамә реквизитлары)
моның белән заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү төзү даталарына гарантиялим:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау

турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең (алга таба - Тәртип) 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акчалар алмый;

эшчәнлекнең бер төре файдалы казылмаларны җитештерү һәм (яисә) сату, шулай ук чыгару һәм (яисә) сату, гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм эчәргә яраклы минераль сулардан тыш, файдалы казылмаларны җитештерү һәм (яисә) сату түгел, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса;

кредит оешмасы, иминият оешмасы (кулланучылар кооперативыннан тыш), инвестиция фонды, дәүләтнеке булмаган пенсия фонды, кыйммәтле кәгазьләр базарының профессиональ катнашучысы, ломбард булып тормый;

продукцияне бүлү турындагы килешүләрдә катнашмый;

уен бизнесы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмый;

Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә каралган очраклардан тыш, валютаны җайга салу һәм валюта контроле турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе нерезиденты булып тормый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә түгел;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юк;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

заявка бирүче юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның заявка бирүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшкуар үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмаган һәм аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән.

Сайлап алуның түбәндәге критерийларына туры килүен өстәмә гарантияли:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

заявка бирелгән датага кече яки урта эшкуарлык субъекты булып тора;

заявка бирелгән датага вәкаләтле орган белән индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында гамәлдәге килешүгә ия (индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентлары һәм идарәче компанияләре өчен);

хисап кварталы өчен Федераль салым хезмәтенә Федераль салым хезмәтенең «Физик затлар турында иминият кертемнәре һәм персоналаштырылган белешмәләр буенча исәп-хисап формаларын, аларны тутыру тәртипләрен, шулай ук аларны электрон рәвештә тапшыру форматларын раслау турында» 2022 елның 29 сентябрендәге ЕД-7-11/878 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча физик затлар турында иминият кертемнәре һәм персоналаштырылган белешмәләр буенча исәп-хисап тапшыра;

сайлап алуны үткәрү елыннан алдагы елда электр энергиясе белән тәэмин итүче оешмага кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләүне гамәлгә ашырды һәм көчәнешнең түбәндәге диапазоннарының (дәрәҗәләренең) электр энергиясен кулланучы булды (кирәклесен ассызыкларга кирәк):

СН-I - көчәнешнең уртача беренче диапазоны (дәрәҗәсе),

СН-II - көчәнешнең уртача икенче диапазоны (дәрәҗәсе),

НН - көчәнешнең түбән диапазоны (дәрәҗәсе).

Җитәкче __________ ____________________________ ____________
(имза) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә субсидия күләмен киметү турында хәбәрнамә

Әлеге хәбәрнамә белән Сезгә агымдагы финанс елда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларының резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен ______(____________________________) сум _____ тиен күләмендә каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитларының җитмәве турында хәбәр итәбез.

(суммасы сүзләр белән)

Сезгә бирелергә мөмкин булган субсидия күләме ___________ (______________________________________) сум тәшкил итә.

(суммасы сүзләр белән)

Сезне «__» ________ 20___ елга кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе расходларын түләү буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының электрон почтасына яисә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасына язма ризалык җибәрүегезне сорыйбыз.

Җитәкче __________ ____________________________ ____________

(имза) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

## Бюджет йөкләмәләре лимитларының калган өлеше күләмендә субсидия алуга ризалык

___________________________________________________________________________
(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

йөзендә ____________________________________________________________,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

____________________________________________________ нигезендә эш итүче
(устав, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры таныклыгы,

___________________________________________________________________________,
ышанычнамә реквизитлары)

бирүгә үз ризалыгымны белдерәм _________________________________________
(юридик затның тулы исеме)

___________________________________________________________________________
индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)

кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә куллану электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга, бюджет йөкләмәләре лимитлары лимитлары аз булу сәбәпле, субсидия күләмен кыскарту турында хәбәргә ярашлы рәвештә, ____________________ (_____________________________________) сум___
(суммасы сүзләр белән)

тиен суммасында ______________ № _____ бюджет йөкләмәләре лимитлары җитәрлек булмауга бәйле рәвештә, бюджет йөкләмәләре лимитлары өлешен каплауга субсидияләр.

Җитәкче _________ ______________________ ___________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

«__» ________ 20__ ел

___________________________________